Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советы

Колай авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

18 июль, 2023 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башлыгының «Олы Дүртөйле авылында җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» карары проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларын билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлегендә (2017 елның 14 декабрендәге 38 номерлы, 2018 елнын 25 маендагы 12 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 50 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы үзгәрешләре белән) иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башлыгының «Олы Дүртөйле авылында җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» карары проекты (алга таба – Проект) буенча иҗтимагый фикер алышуларын билгеләү (кушымта)

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елнын 26 июлендә, 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Питрәч ав., Совет ур., 18 нче йорт адрес буенча;

2.3. адресы буенча, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: 422774, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авыл җирлеге, Колай ав., Профсоюз ур., 24А й. адресы буенча

(дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

2.4. Колай авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында 2023 елның 24 июлендә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай ур., Профсоюз ур., 24А йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр)Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проектның демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештырырга.

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы — Н.В. Поповская

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КУЛАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СОВЕТ КУЛАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1633000850

Колай авыл җирлеге башлыгы
карарына кушымта
18.07.2023 ел № 2

Проект

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советы

Колай авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

___ _____ 2023 ел № __

Олы Дүртөйле авылында җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзәлешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 2023 елның ____ _________ иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә әзерләнгән тәкъдимнәрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. Җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирергә:

- ж/к кадастр номеры 16:33:050801:686, мәйданы 375 кв.м., адресы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авыл җирлеге, Олы Дүртөйле авылы - индивидуаль торак зонасында « Җәмәгать туклануы » (Ж1),

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская